**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«6» апрель 2015 ел № 36/12

**Муниципаль унитар предприятиеләрдә һәм муниципаль учреждениеләрдә урнашкан күчемсез һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне сату һәм арендага бирү буенча килешүләрне килештерү буенча карарлар кабул итү тәртибе турында**

Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, «Автоном учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 январендәге 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 2006 елның 28 июлендәге 7-ФЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы, ПР-317 номерлы Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы утырышының 2014 елның 3 декабрендәге беркетмәсенең 8.1 пунктчасы нигезендә,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Муниципаль унитар предприятиеләрдә һәм муниципаль учреждениеләрдә урнашкан күчемсез һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне сату һәм арендага бирү буенча килешүләрне килештерү буенча карарлар кабул итү тәртибен кушымта нигезендәрасларга.
2. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе В.Г. Хаҗиев